ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
Г.Тукай исемендәге Ашытбаш урта гомуми белем мәктәбе

# “Юлда сак бул!”




Арча районы Г.Тукай исемендәге Ашытбаш урта гомуми белем мәктәбенең башлангыч классслар укытучысы Ибраһимова Люция Фәрид кызының ачык чара эшкәртмәсе.

**Тема: «Юлда сак  бул!»**

***Максат:*** 1. Балаларның юл йөрү кагыйдәләрен ничек үзләштерүләрен, юл билгеләрен «укый белүләрен» ачыклау.

2. Светофор төсләрен аера белүләрен, шуның буенча ничек хәрәкәт итүләрен тикшерү.

3. Юлларда игътибарлы булырга, юл йөрү кагыйдәләренә буйсынырга өйрәтү: дуслык, бердәмлек, бер—береңә игътибарлы, ярдәмчел, әдәпле булуларына ирешү.

***Үткәрү формасы:   Кичә-уен***

***Җиһазлау:*** залны бизәү өчен: светофор төсләре белән язылган плакатлар, юл билгеләре; презентация, сигнал карточкалары, уенчык машиналар, наутбук, диск,

Кичәгә матур итеп зал бизәлгән, әкрен генә музыка тавышы ишетелә.

***Кичә барышы***

***Җыр "Күңелле сәяхәт"***

Татар халкында борынгыдан килгән бер гадәт яши: юлчыларга юлга чыкканда "Хәерле юл!" дип озатып калу һәм "Исән – сау кайттыңмы" дип каршы алу. Әйе, көннәребез имин үтсен, юлларыбыз уң булсын иде. Һәр яңа көн тугач кемдер мәктәпкә, кемдер эшкә ашыга. Без җәяүләп тә, машиналарга утырып та, велосипедлар белән дә хәрәкәт итәбез. Димәк, безнең һәркайсыбыз юлга чыга, юллар белән очраша.

Көн буламы төн буламы
Юлга чыгып китәбез
Ничә мең чакрымнар үтеп,
Кабат кайтып керәбез

Бүгенге көндә юлларга чыгу, аны хәвеф – хәтәрсез, исән – имин үтәр өчен тиз фикер йөртә белү, тирән белемнәр, аларны дөрес куллану күнекмәләре кирәк.

Юлда төрле хәлләр була
Яңгыр да бураны да
Ходай зинхар исән йөрик
Без синең кулда гына.

Карап-карап торам да мин,
Уйлап-уйлап торам да,
Куркып куям: ай-һай кыен
Йөрүләре урамда!

Урамның теге ягына
Мөмкин түгел үтүе:
Урам тулы троллейбуслар,
Машиналар көтүе.

Әллә кайсы җирдән генә
Трамвай, йә машина,
Йә булмаса, мотороллер
Килеп чыга каршыңа!

Йә сызгырта сыбызгысын
Полицийский абый.
Йөри белмәсәң урамда
Ул әллә каян таный!

Ялт чыгасың тротуарга —
Сизелми дә калына.
Бигрәк авыр шул шәһәрдә
Авыл малайларына!

Алмаз исә уйламый да —
Ят түгел аңа кала.
Машиналы урамда ул
Туйганчы йөри ала.

Бу шау-шулы урамнарда
Алмаз да йөрми тормый.
Тик урам аша чыгулар
Алмазга берни тормый.

Башта сул якка карый ул,
Аннан уң якка карый.
Аннары миңа борыла: —
Хәзер чыксак та ярый!

Ни булды соң «Волга»ларга,
«ГАЗ»га, «МАЗ»га, «КамАЗ»га
Выжлап килеп туктыйлар да
Юл бирәләр Алмазга.

Баксаң, алда светофор
Тора икән лә сакта.
Чыгалар икән урамнан
Яшел ут янган чакта.

КЫЗЫЛ, САРЫ УТ ЯНГАНДА
ЯРАМЫЙ, ДИ, ЧЫГАРГА.
ЯНГАН ЧАКТА ЯШЕЛЕ
КИРӘК ИКӘН ЧЫГАРГА...

**Җыр “Светофор”**

**Балалар:** (идәннән язу табып ала) Бу нәрсә? Ниндидер язу... (укыйлар) "Без - юл билгеләре илендә яшәүчеләр зур бәхетсезлеккә юлыктык. Һәм безнең илдә һәрвакыт юл һәләкәтләре булып кына тора. Безгә ярдәм итегез зинһар.”

Тизрәк, әйдәгез ярдәм итик. Нәрсә булганын белик. Юл билгеләре юк, светофор да күренми **(Шүрәле керә.)**

**Шүрәле:** Ха-ха! Ярдәм көтәләр. Бернинди ярдәм булмаячак! Хе, кем ярдәм итсен инде аларга!?

Балалар: Без ярдәм итәбез!

**Шүрәле:** ә сез кемнәр?

А.Б. Без укучылар.

**Шүрәле:** Ярдәм итәсегез килә мени ? Юк! Сез светофорны да, юл билгеләрен дә тапмаячаксыз. Мин бик яхшы яшердем. **(Шүрәле китә)**

**А.Б.** Алайса, вакытны әрәм итмик, юлга кузгалдык.
**(Аларның каршысына юл билгесе очрый, елый, түшендә юл билгесе капланган.)**

**А.Б.** Кем бу?

**Юл билгесе:** Мин - Юл билгесе. Мин кешеләргә юл йөрү кагыйдәсен күрсәтә алмыйм хәзер. Мин бары тик табышмакларга җавап табучы булганда гына ачыла алам.

(Табышмакларны алып баручыга бирә)
**А.Б.**1. Барам-барам очы юк.(Юл)
2.Ягымлы да, усал да ул
Аны белә бөтен җир
Киң һәм матур урамда
Ул кирәкле командир.(Светофор)
3.Тәрәзәле һәр ягы
Җиргә тими аягы
Сыртында бар дугасы (Трамвай)
4. Уф-уф сулар
Уфтанса да алып китәр,
Барыр җиреңә илтер.(Поезд)
5.Аяклары түгәрәк
Куышалар тәгәрәп,
Үзем утырам, үзем чабам,
Әй чабабыз, бергәләп.(Велосипед)

**(Юл билгесе тамгасын ача)**

**Юл билгесе:** Мине беләсезме, мине кайда очратырга була?

**Балалар:** Борылышта. **(Мыраужан керә)**

**Мыраужан:** Исәнмесез, мин Мыраужан.

**А.Б**. Син юл йөрү кагыйдәләрен беләсеңме? Әйдәгез, тикшереп карыйбыз. Урам аша ничек чыгарга?

**Мыраужан:** Ничек инде , дүртаяклап.

**А.Б**. Балалар , дөресме?

Укучы. Юк. Светофорда яшел төс янгач, җәяүлегә чыгырга мөмкин дигән тамга булганда, җир асты һәм җир өсте юлларыннан чыгарга мөмкин.

**А.Б**. Сиңа икенче сорау. Автобустан төшкәч , аны ничек әйләнеп узарга?

**Мыраужан:** Ә нигә әйләнеп торырга? Сикереп тә чыгарга мөмкин бит, ә тагы да яхшысы тәгәрмәчләр арасыннан узарга мөмкин.

**А.Б**. Песи буталып бетте. Автобустан, троллейбустан төшкәч транспорттның артыннан, ә троллейбустан төшкәч алдыннан аркылырга кирәк.

**А.Б**. Сиңа тагын бер сорау. Юлда уйнарга ярыймы?

**Мыраужан:** Нәрсәне бит. Шахмат уйнарга ярамый. Машиналар бөтен фигураларны таптап бетерә, ә менә туп белән уйнарга ярый.

**А.Б**. Ә сез, балалар, аның белән килешәсезме?

Укучы : Юлда уйнарга ярамый, хәтта юлга якын урыннарда да уйнау тыела.

**Шүрәле керә**: Тыңлама син аларны. Ничек рәхәт юлда уйнавы. Туктале, нигә алар сиңа сораулар бирәләр, үзләре берәр нәрсә беләләрме соң?

**Мыраужан:** Ничек кенә беләләр әле! Миңа алар белән күңелле, алар бик күп белә, зирәк балалар. Светофор турында да бик күп беләләр.
**1 укучы:** Әйе, светофор элек хәзерге сыман булмаган. Алар башта менә нинди булган. 4 яктан 3 төрле пыяла: яшел, сары, кызыл. Алар буенча әкрен генә зур кара ук хәрәкәт иткән. Алар белән хәрәкәтне көйләү кыен булган. Хәзерге автомат светофорлар бик уңайлы.

**Мыраужан:** Мин сезгә бер серне әйтәм. Мин ничек юл билгеләрен коткарырга икәнен беләм. Берничә тылсымлы сүз әйтергә кирәк.
Юл билгеләре! Юл билгеләре! Кайда сез?! Тизрәк безнең янга килегез!

***(Юл билгеләре тезелеп баса.)***

1. Җәяүлеләр юлы аша
   Чыгыгыз каршы якка
   Зебра сызыклары кебек
   Буялган ул юл акка





2. Ә бу билге йөрүне тыя!
   Кайгы була күрмәсен
   Монда җәяүле йөрмәсен.



3. Бу кисәтә шоферларны:
   Акрын, игътибар!
   Якында гына балалар,
   Мәктәп, бакча бар.



4. Дуслар, бу билге
   Бик кирәк Юлчыларга.
   Мөмкин шушы тирәдә
   Тамак ялгап чыгарга.



**Юл билгеләре:** Без шат, безне коткардылар, без һәркемгә ярдәмгә әзер!

**Шүрәле**: Нигә шатланасыз, юл билгеләре табылса да, светофор юк бит әле. Светофор турында матур итеп шигырь сөйләсәгез генә Светофорны таба алырсыз .
**Укучы:** Янып тора алмашлап өч күзең
Әйтеп тора безгә өч сүзне:
- Кузгалма!- ди кызыл күзең,
- Сабыр! – ди сары күзең,
- Ярый! – ди яшел күзең.

**(Светофор керә)**
**Шүрәле:** Бетте, бөтенесе бетте. миңа каршы барысы. (китә)
Светофор: Рәхмәт, дусларым, коткардыгыз мине. Минем белән һәм башка юл билгеләре белән дә һәрчак дус булыгыз.

***Юлда йөрсәң, бул өлгер,***
***Юл кагыйдәсен нык бел.***
***Светофорның һәрбер төсен,***
***Юлның билгеләрен бел.***
***Өйрәник бергә дусларым***
***Юл йөрү кагыйдәсен.***

***Һәрберегез имин йөрсен***
***Бәла- каза күрмәсен.***
***Юл билгеләрен белгәндә,***
***Алар кушканча йөргәндә,***
***Тыныч булыр юлыгыз***
***Исән – имин булыгыз!***

**1.а.б..” Ярый, ярамый” уены**

Хәзер “ Ярый, ярамый “ дигән уен уйнап алабыз. Пассажирларга үтәргә ярый торган эш булса- атлыйбыз, ярамый торган эш булса - чүгәлибез.

-юлны аркылы чыкканда башта сулга карарга ( ярый )
-юлны теләсә каян чыгарга ( ярамый )
-тукталышта этешә - төртешә уйнарга ( ярамый )
-троллейбуста буш урын булса, утырырга (ярый )
-трамвайда өлкәннәргә урын бирергә ( ярый )
-автобусның ишегенә терәлеп барырга ( ярамый)
-Светофорда яшел ут янганда юл аркылы чыгарга ( ярый)
-Юлны теләсә кайдан чыгарга (ярамый)
-Велосипед белән теләгән урында йөрергә (ярамый)
-Автобус ишегенә терәлеп барырга (ярамый)
-Автобус яки машина артына тотынып барырга (ярамый)
-Җәяүлегә машина хәрәкәтенә каршы барырга (ярый)

**1.а.б**. “Сорау – җавап” **бәйгесе.**

1.Автобус көтү урыны. (тукталыш)
2.Җәяү йөрүче кем дип атала? (җәяүле)
3.Светофорның ничә төсе бар? (3)
4.Машина юлы аша ничек чыгарга? ( җәяәүлеләр чыгу (пешеходный переход) юлы)
5.Велосипедта ничек йөрергә ярамый? (кулны җибәреп)
6.Җәяүлеләр өчен яшел ут янса, машиналар өчен нинди төс янар?( кызыл)
7.Җәяүле юлы.( тротуар)
8.Автобусны ничек әйләнеп узарга? (әйләнеп узарга ярамый, киткәнен көтеп торырга, һәм куркынычсыз урыннан чыгарга)
9.Нинди транспорт төрләре бар? (Су, һава, коры җир транспорты)
10.ЮХИДИ ничек була? (Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе)

Зур теләк белән өйрән син,
Өлкәннәрне карап тор.
Машина узганын көтми-
Йөгермә син тизрәк.
Моны белү һәр балага,
Кайда йөрсә дә кирәк.

Сак йөрегез зур юлларга
Юлыкмый хәвефләргә
Хәерле юл бар-чагызга
Киләчәк гомерләргә

Сак йөрегез зур юлларга
Юлыкмый хәвефләргә
Куелмасын һәйкәлләр дә
Озын юл буйларында.